СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**27 октября 2025 ел** **№10**

**Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Урта Пошалым авылында граждан-нарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге Уставының 25 статьясы, Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Урта Пошалым авылында Урта Пошалым авылы, Вахитов урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан Урта Пошалым мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 13 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Урта Пошалым авылында Урта Пошалым авылы, Вахитов урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан Урта Пошалым мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 13 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга:
1 нче этап: Х.Такташ урамында яшәүчеләр;
2 нче этап: Вахитов, Сәйдәшев урамнарында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Урта Пошалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юлның буй профилен төзәтү; кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту)
- урамнарны яктырту җайланмасы (баганаларны сүтү һәм монтажлау, урамнарны яктырту өчен чыбыклар сатып алу; яктырткычлар сатып алу)
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм алар янындагы

территорияне төзеклəндерү (һəйкəлне бер урыннан икенче урынга демонтажлау һəм монтажлау һəм аны төзеклəндерү)?

Аерым мəсьəлəлəр буенча экономия барлыкка килгəн очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгелəнгəн башка мəсьəлəлəрне хəл итү өчен җибəрергə рөхсəт итəргə.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

5. Арча муниципаль районы Үрнəк авыл җирлеге Урта Пошалым авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мəсьəлəсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Үрнəк авыл җирлеге башкарма комитетын билгелəргə.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рəсми хокукый мəгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белəн бастырып чыгарырга һəм халык күплəп җыела торган урыннарда мəгълүмат стендына Уртадагы адрес буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Пошалым авылы, Вахитов урамы, 15 нче йорт.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнəн үз көченə керə.

Үрнəк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков